**Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге**
**Башкарма комитеты**
**карары**

**№6802**
**15.10.2021**

Башкарма комитетның 2021 елның 3 мартындагы 1441 номерлы карары белән расланган муниципаль хезмәтләр исемлегенә үзгәрешләр кертү турында

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Электрон формада, дәүләт йөкләмәсе (заказы) урнаштырыла, Татарстан Республикасы дәүләт учреждениеләре тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтләр һәм социаль әһәмияткә ия дәүләт хезмәтләре күрсәтүгә күчү буенча чаралар планын раслау турында» 2021 елның 13 апрелендәге 242 номерлы карары, Шәһәр Советының 2007 елның 21 февралендәге 19/8 номерлы карары белән расланган Муниципаль хокукый актлар системасы турында нигезләмәнең 5.24, 5.25 пунктлары нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Башкарма комитетның 2021 елның 3 мартындагы 1441 номерлы карары (Башкарма комитетның 2021 елның 31 маендагы 3645 номерлы, 2021 елның 1 июлендәге 4402 номерлы карарлары редакциясендә) белән расланган муниципаль хезмәтләр исемлегенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2. 21 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«21. «Россия Федерациясендә автомобиль юллары турында һәм юл эшчәнлеге турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2007 елның 8 ноябрендәге 257-ФЗ номерлы Федераль законның 31 статьясы белән билгеләнгән вәкаләтләр нигезендә, автомобиль юлларында авыр һәм (яки) эре габаритлы транспорт чарасы хәрәкәтенә махсус рөхсәт бирү»;

2) 23, 26, 28 пунктлар үз көчен югалткан дип танырга;

3) 38 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«38. Җир участокларын милеккә бушлай бирү хокукына ия затлар буларак, гражданнарны исәпкә кую»;

4) 45 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«45. Шәһәр төзелеше эшчәнлеген тәэмин итүнең мәгълүмат системасындагы мәгълүматларны бирү»;

5) 60 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«60. Мәгълүмати элмә такта урнаштыру, элмә такта урнаштыруның дизайн-проектын килештерү»;

6) түбәндәге эчтәлектәге 90 пункт өстәргә:

«90. Муниципаль милектәге җир участогын сатулар үткәрмичә милеккә, арендага, даими (сроксыз) файдалануга, түләүсез файдалануга бирү».

3. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны «Челнинские известия», «Шәһри Чаллы» газеталарында бастырып чыгаруны һәм аны «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru), Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Аппараты Җитәкчесе Г.К. Әхмәтовага, Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары Н.А. Кропотовага йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Ф.Ш. Салахов